| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ГЛАВА КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11.04.2024 Олы Кайбыч ав. № 21

«Кайбыч муниципаль районы Башлыгы һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы аппаратының вазыйфаи затлары тарафыннан гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибен раслау турында» 2016 елның 01 декабрендәге 92 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 09 декабрендәге 124-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә КАРАР ИТӘМ:

1. «Кайбыч муниципаль районы Башлыгы һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы аппаратының вазыйфаи затлары тарафыннан гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибен раслау турында» 2016 елның 01 декабрендәге 92 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башлыгы һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы аппаратының вазыйфаи затлары мөрәҗәгатьләрен карау эше тәртибендә:

1) 1.2 пунктның 3 абзацында «электрон почта адресы» сүзләреннән соң «яисә Бердәм порталда шәхси кабинет адресы» сүзләрен өстәргә;

2) 2.15 пунктның 2 абзацында «яисә Бердәм порталда шәхси кабинетлар адресларына» сүзләрен өстәргә;

3) 4.5 пунктының 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Телдән мөрәҗәгатьтә шәхси кабул итү барышында бәян ителгән фактлар һәм хәлләр ачык күренеп тора һәм өстәмә тикшерү таләп итми торган очракта, гражданның ризалыгы белән мөрәҗәгатькә җавап кабул итүне гамәлгә ашыручы вазыйфаи зат тарафыннан телдән бирелергә мөмкин, бу турыда кабул итү карточкасында языла, ул мөрәҗәгать итүченең шәхси имзасы белән раслана. Гражданның телдән җавапка ризалыгы булмаса яисә мондый ризалыкны шәхси имзасы белән раслаудан баш тартса, мөрәҗәгатьтә куелган сорауларның асылы буенча язмача җавап бирелә»;

4) түбәндәге эчтәлекле 4.7.1 пункты белән тулыландырырга:

«4.7.1 Гражданнарны шәхси кабул итү өчен билгеләнгән көннәрдә һәм сәгатьләрдә органнарда чираттан тыш шәхси кабул итүгә хокукка I, II төркем инвалидлар, инвалид балалар һәм шундый балаларны озатып йөрүче затлар ия.

Чираттан тыш шәхси кабул итүгә хокукка бер үк вакытта берничә граждан ия булса, күрсәтелгән гражданнарны кабул итү аларның шәхси кабул итүгә килү тәртибендә гамәлгә ашырыла.»;

5) 4.8. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.8. Гражданнарны органнарда шәхси кабул итү өчен билгеләнгән көннәрдә һәм сәгатьләрдә беренче чираттагы шәхси кабул итүгә түбәндәгеләр хокукка ия:

1) Бөек Ватан сугышы ветераннары, Россия Федерациясе Геройлары, Советлар Союзы Геройлары, Дан орденының тулы кавалерлары, Социалистик Хезмәт Геройлары, Россия Федерациясе Хезмәт Геройлары, сугышчан хәрәкәтләр ветераннары;

2) ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затлар, шулай ук әгәр алар мондый балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итүгә һәм яклауга бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итсәләр, аларның законлы вәкилләре;

3) инвалидларның, инвалид балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итүгә бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итсәләр, I, II төркем инвалидларның, инвалид балаларның законлы вәкилләре һәм вәкилләре;

4) очрашуга өч яшькә кадәрге балалар белән килгән гражданнар.

Беренче чираттагы шәхси кабул итүгә хокукка берьюлы берничә граждан ия булса, күрсәтелгән гражданнарны кабул итү аларның шәхси кабул итүгә килү тәртибендә гамәлгә ашырыла.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кайбыч муниципаль районы Советы Аппараты Җитәкчесе Айзатуллова Р.Г.га йөкләргә.

А.И.Рәхмәтуллин